РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Исполнительный комитет
Вахитовского сельского поселения
Азнакаевского
муниципального района

ул. Центральная, д. 30, Азнакаевский район,
п.Победа, 423312,
тел./факс (885592)42-1-38
E-mail: Vahit.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Азнакай муниципаль районы
Вахитов авыл җирлеге
башкарма комитеты

Үзәк ур., 30 йорт, Азнакай районы, Җиңү
бистәсе, 423312,
тел./факс (885592)42-1-38
E-mail: Vahit.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«15» декабрь 2022ел.** **№ 22**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге башкарма комитетының 26.01.2022 елның 3 номерлы «Торак мөнәсәбәтләре өлкәсендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл мөнәсәбәтләре өлкәсендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Хезмәт торак урынына наем шартнамәсе буенча муниципаль торак фондында гражданнарга торак урыннары бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә бәян итәргә.

1.2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлегенең махсуслаштырылган торак фонды составына кертү һәм торак урыннарны төшереп калдыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын, әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http//aznakayevo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык Г.И. Аскарова